**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ XLII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 72**

***Югары Табын авылы*** ***"29" нчы март, 2024 нче ел***

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 маендагы 55 номерлы «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Федераль законнарына туры китерү максатыннан, прокурорның 2024 елның 18 мартындагы 02-08-01-2024 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында» 2023 елның 23 маендагы 55 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 бүлекнең 4.5. пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча белән тулыландырырга:

«13) Җирлек башкарма комитеты җитәкчесенә, эш бирүче карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш, анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).»;

1.2. 5.1. пунктның 8 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, яисә документларның һәм (яисә) белешмәләрнең, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәве турында таныклый торган белешмәләрне тапшырганда;»;

1.3. 8.3. пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт турындагы федераль законнар нигезендә анкета;»;

1.4. 8 бүлекнең 8.4. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8.4. Муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлар (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин.»;

1.5. 17.1. пунктындагы 11 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

1.6. 9 бүлекнең 9.6. пунктын төшереп калдырырга;

1.7. 3 бүлекнең 3.10. пунктын төшереп калдырырга;

1.8. 17 бүлекнең 17.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.2. Муниципаль хезмәт өчен кадрларны шартнамә нигезендә әзерләү муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы** **Р.Ш. Кыяметдинов**